**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.03.2019 Казан ш. № 83

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү очрагы турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү тәртибен раслау турында

2008 елның 25 декабрендә кул куелган 273-ФЗ «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законының 9 маддәсе нигезендә

**боерык бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү очрагы турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итүнең теркәлә торган тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне үз артымда калдырам.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
2019 елның 19 мартында
кул куелган 83 номерлы
боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында
Татарстан Республикасы Дәүләти гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү очрагы
турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү
ТӘРТИБЕ

1. Татарстан Республикасы спорт министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләти гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү очрагы турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү тәртибе (алга таба – Тәртип) 2008 елның 25 декабрендә кул куелган 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында » Федераль законның 9 маддәсендәге 5 өлеше нигезендә эшләнгән.

Тәртип эшкә алучы вәкиле булып Татарстан Республикасы спорт министры (алга таба – министр) торган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре, министрлык) коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү очрагы турында хәбәр итү процедурасын рәсмиләштерә.

2. Коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать очраклары турында хәбәр итү, бу очраклар буенча тикшерү үткәрелгән яки үткәрелә торган очраклардан тыш, гражданлык хезмәткәренең вазифаи (хезмәт) бурычы булып тора.

3. Коррупциячел хокук бозу кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү очрагы турында эшкә алучы вәкиленә белдерү кәгазе (алга таба – Белдерү) әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасы нигезендә гражданлык хезмәткәре тарафыннан язмача формада төзелә.

Белдерүдә түбәндәге мәгълүматлар чагылдырылырга тиеш:

Белдерү җибәргән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, били торган вазыйфасы һәм структур бүлекчәсе, яшәү урыны һәм телефоны;

Министрлыкның гражданлык хезмәткәренә нинди дә булса затларның хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү очраклары очрагы (очраклары турында мәгълүм булды) булган хәлләрне тасвирлау (датасы, урыны, вакыты, башка шартлар);

гражданлык хезмәткәренә кергән коррупцион хокук бозу кылуга тарту турында дәлилли торган мөрәҗәгатьнең (зат тарафыннан хезмәткәргә карата эшләнгән гамәлләр, тәкъдимнәр, гаризалар, таләпләр, башка формада мөрәҗәгать итү гамәлләре) төгәл тасвирламасы, шулай ук гражданлык хезмәткәрен җәлеп итәргә җыенган коррупцион хокук бозу билгеләренә ия булган гамәлләр тасвирламасы;

коррупцион хокук бозуларга җәлеп итәргә җыенган физик (юридик) зат турында барлык билгеле булган мәгълүмат;

коррупцион хокук бозуларга тарту ысулы һәм шартлары (сатып алу, янау, алдау һәм башкалар), шулай ук затның коррупцион хокук бозулар кылу турында тәкъдимен кабул итүдән баш тарту (килешү) турында мәгълүмат;

Белдерүнең прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына (нинди) хәбәр җибәрү датасы.

Белдерүгә гражданлык хезмәткәрен коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итү шартларын раслый торган барлык булган материаллар теркәлә.

4. Мөрәҗәгать министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) исеменә языла һәм коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) кичекмәстән тапшырыла, ә күрсәтелгән тәкъдим эш вакытында булмаса, хезмәт итү урынына килеп җитүгә үк кичекмәстән җиткерелә.

Гражданлык хезмәткәре вазыйфаи (хезмәт) бурычларын башкаруда булмаса яисә даими хезмәт урыны чикләреннән читтә булганда, белдерү почта аша, факсимиль элемтә каналлары яисә башка мөмкин булган электрон элемтә каналлары аша җибәрелә ала, аннары, хезмәткә әйләнеп кайткач, Җаваплы затка Белдерүнең

оригиналын тапшыра.

5. Җаваплы зат Белдерүне Тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә дәүләт хезмәткәрен коррупцион хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү очраклары турында эшкә алучы вәкиленә Белдерүләрне теркәү журналында (алга таба – Журнал) терки.

6. Журналда белдерүне теркәгәннән соң гражданлык хезмәткәренә Белдерү кәгазен кабул иткән зат турында мәгълүматлар һәм аны теркәү датасы күрсәтелгән Белдерү күчермәсе тапшырыла. Мөрәҗәгать почта аша килгән очракта, Белдерү күчермәсе гариза җибәргән гражданлык хезмәткәренә заказлы хат белән җибәрелә.

Белдерүне теркәүдән баш тарту, шулай ук Белдерүнең күчермәләрен бирмәү рөхсәт ителми.

Алынган мәгълүматларның конфиденциальлеге 2006 елның 27 июленнән 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында « Федераль законы таләпләре нигезендә тәэмин ителә.

7. Җаваплы зат Белдерүне теркәү көнендә эчке эшләр органнарына яки башка дәүләт органнарына җибәрү турында карар кабул итү өчен аны министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) карауга тапшыра.

8. Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Белдерүне эчке эшләр органнарына яисә башка дәүләт органнарына җибәрү турында Карар кабул иткәндә, Җаваплы зат мондый карар кабул ителгән көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча Белдерүне, материалларны теркәп, шунда җибәрә.

9. Эшкә алучы вәкиленә, прокуратура органнарына яки башка дәүләт органнарына аны коррупциячел хокук бозулар кылуга җәлеп итү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр иткән гражданлык хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яклавында тора.

10. 2008 елның 25 декабрендә кул куелган 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 9 маддәсе нигезендә Министрлык гражданлык хезмәткәренең коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту фактлары турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү бурычын үтәмәве аны дәүләт хезмәтеннән азат итү яки аны Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төр

җаваплылыкка тартуга китерә торган хокук бозу булып тора.

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләти гражданлык хезмәткәрен коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү очрагы турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү тәртибенең

1 нче кушымтасы

Татарстан Республикасы спорт министры _______
(эш бирүченең вазыйфасы)

_______________________________________________
(эшкә алучы вәкиленең Ф.И.Аи.)

_______________________________________________
(дәүләт гражданлык хезмәткәренең Ф.И.Аи., вазыйфасы, тору _______________________________________________дан урыны, телефоны)

Коррупцион хокук бозулар кылуга
тарту максатларында мөрәҗәгать итү очрагы турында
эшкә алучы вәкиленә
БЕЛДЕРҮ

Коррупцион хокук бозулар кылуга тарту максатларында тарафыннан ________

_______________________________________________________________________________
________ (хокук бозу кылуга тартучы затның Ф.И.Аи., вазыйфасы, аның турында билгеле булган барлык мәгълүматлар)

_______________________________________________________________________________

мөрәҗәгать итү очрагы турында хәбәр итәм.

Хокук бозу кылуга тарту минем тарафтан түбәндәгеләрне эшләү максатында
_______________________________________________________________________________
(зат тарафыннан коррупцион хокук бозулар кылуга тартуны раслый торган гражданлык хезмәткәренә кергән
_______________________________________________________________________________
мөрәҗәгатьнең (гамәл) тулысынча тасвирламасы күрсәтелә
_______________________________________________________________________________
хезмәткәргә карата башкарылган мөрәҗәгать (гамәл) (тәкъдим, гариза, таләп, башка төрле формада мөрәҗәгатьнең
_______________________________________________________________________________
тулысынча тасвирламасы, шулай ук гражданлык хезмәткәрен кылуга тартырга җыенган коррупцион хокук бозулар
_______________________________________________________________________________
билгеләренә ия булган гамәлләрнең тасвирламасы)

Хокук бозулар кылуга тарту
_______________________________________________________
(коррупцион хокук бозуларга тарту ысулы һәм шартлары (сатып алу, янау, алдау һәм һ.б.), шулай ук затның коррупцион хокук
_______________________________________________ юлы белән гамәлгә ашырылды.
бозулар кылу турында тәкъдимен кабул итүдән баш тарту (килешү) турында мәгълүмат

Хокук бозулар кылуга тарту
_______________________________________________

(телефоннан сөйләшү, шәхси очрашу вакытында, смс-хәбәр белән һ.б.)

булды.

Хокук бозулар кылуга тарту 20__ елның «__» __________ ____ сәгать минутта ______________________________________________________________________ булды.

(шәһәр, адрес)

Шулай ук ______________________________________________________________________

(прокуратура органнарына һәм башка дәүләт органнарына (нинди) белдерү датасы

______________________________________________________________________

белдерүем турында хәбәр итәм.

__________ ______________ ________________________

(дата) (имза (имзаның расшифровкасы)

Татарстан Республикасы спорт министрлыгында Татарстан Республикасы Дәүләти гражданлык хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү очрагы турында эшкә алучы вәкиленә хәбәр итү тәртибенең

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында
Татарстан Республикасы Дәүләти гражданлык хезмәткәрен
коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында
мөрәҗәгать итү очрагы турында эшкә алучы вәкиленә
белдерүләрне теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № | Белдерүне теркәү датасы | Белдерү бирүченең Ф.И.Аи, вазыйфасы | Белдерү бирүченең имзасы | Теркәүченең Ф.И.Аи. | Теркәүченең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |